КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 25 декабрь г.Казань № 1221

Инвалидлар һәм халыкның башка аз хәрәкәтләнүче төркемнәре тормыш эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендә һәркем файдалана алуны тәэмин итү өлкәсендәге чараларны финанс белән тәэмин итү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2011 – 2020 елларга «Уңайлы мохит» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2015 елның 1 декабрендәге 1297 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Инвалидлар һәм халыкның башка аз хәрәкәтләнүче төркемнәре тормыш эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендә һәркем файдалана алуны тәэмин итү өлкәсендәге чараларны финанс белән тәэмин итү тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетның 2018 ел, 25 декабрь, 1221 нче карары белән расланды

Инвалидлар һәм халыкның башка аз хәрәкәтләнүче төркемнәре тормыш эшчәнлегенең өстенлекле өлкәләрендә һәркем файдалана алуны тәэмин итү өлкәсендәге чараларны финанс белән тәэмин итү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2021 елларга Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында "2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары белән расланган «2014 – 2018 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарын социаль яклау» дәүләт программасының «Уңайлы мохит " ярдәмче программасын (алга таба – Ярдәмче программа) гамәлгә ашыру кысаларында инвалидлар һәм халыкның башка аз хәрәкәтләнүче төркемнәре эшчәнлегенең өстенлекле объектларын һәм хезмәт күрсәтүләрен тәэмин итү өлкәсендә чараларны (алга таба – чаралар) финанслар белән тәэмин итү механизмын билгели.

2. Чараларны финанслар белән тәэмин итү чараларны финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган субсидияләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла.

3. Әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән акчалар Ярдәмче программаны җаваплы башкаручыларга (алга таба – Акчаларны баш бүлүчеләр) чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итүгә тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бирелә, аларны финанслау максатында субсидия бирелә.

4. Акчаларны баш бүлүчеләр ай саен, һәр айның бишенче числосына кадәр Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына (алга таба – министрлык) Россия Федерациясе бюджет классификациясе кодларын күрсәтеп, агымдагы айга чараларны гамәлгә ашыруга финанс чараларына ихтыяҗ турындагы тәкъдимнәрне юллыйлар.

5. Министрлык ай саен, һәр айның 10 числосына кадәр, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Акчаларны баш бүлүчеләр киселешендә чараларны гамәлгә ашыру чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә гариза җибәрә (алга таба – явка).

6. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән (алга таба – Казначылык) алынган бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм субсидияләрне финанслауның иң чик күләмнәре турындагы мәгълүмат нигезендә биш эш көне эчендә Казначылык аша финанс чыгымнары расписаниесен Министрлык гаризалары буенча Акчаларны баш бүлүчеләргә тапшыра.

7. Субсидияләрне тоту Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетлар аша Акчаларны баш бүлүчеләр тарафыннан гамәлгә ашырыла.

8. Акчаларны баш бүлүчеләр Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетыннан акча күчерү «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында»2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән дәүләт контрактларына нигезләнеп башкарыла.

9. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы ел саен, хисап елыннан соң килүче елның 10 гыйнварына кадәр субсидияләрне куллануның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре зурлыкларына ирешү турында Министрлыкка хисап җибәрәләр.

10. Акчаларны баш бүлүчеләр квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 10 числосына кадәр Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына финанслашу максатында субсидия бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра.

11. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 12 числосына кадәр финанслашу максатында субсидия бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру турында Министрлыкка хисап тапшыра.

12. Министрлык түбәндәгеләрне тапшыра:

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына:

ел саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 15 гыйнварына кадәр электрон документ рәвешендә «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында – субсидия куллануның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре зурлыгына ирешү турында хисап;

квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 15 числосына кадәр электрон документ рәвешендә «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында – финанслашуга субсидия бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру турында хисап;

Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгына һәм Россия Федерациясе Спорт министрлыгына:

ел саен, хисап елыннан соң килүче айның 15 гыйнварына кадәр – субсидия куллану нәтиҗәлелеге күрсәткечләре зурлыгына ирешү турында хисап;

квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 15 числосына кадәр – финанслашуга субсидия бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру турында хисап.

13. Әлеге Тәртипнең 9 – 12 пунктларында күрсәтелгән хисаплар Россия Федерациясе Финанс министрлыгының

федераль бюджеттан субсидия бирү турында «Россия Федерациясе субъекты бюджетына федераль бюджеттан субсидия бирү турында килешүнең үрнәк формасын раслау турында» 2017 елның 13 декабрендәге 232н номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе субъекты бюджетына федераль бюджеттан

субсидия бирү турында килешүнең үрнәк формасына 6 нчы һәм 7 нче кушымталарга ярашлы формалар буенча тапшырыла.

14. Акчаларны баш бүлүчеләр тапшырыла торган хисап мәгълүматларының дөрес булмавы һәм субсидияләрне максатсыз файдалану өчен закон нигезендә җавап тота.

15. Бирелгән субсидиянең максатчан кулланылышын контрольдә тоту Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.